**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-38, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
_03.10.2019г._

КАРАР
_ПР-207_

Инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларны раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә, 2010 елның 27 июлендәге Федераль закон таләпләрен үтәү йөзеннән, №210-ФЗ "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында“ Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" 02.11.2010 № 880,Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1.Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 2014 елның 25 февралендәге ПР-118 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Л. Ф. Нурлыева

Татарстан Республикасы Актаныш
муниципаль районы башкарма
комитеты
карары белән расланган
03.10.2019 № ПР-207

**Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Хезмәт алучылар: физик һәм юридик затлар (алга таба – гариза бирүчеләр).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәт башкаручы - Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге (алга таба-Бүлек).

1.3.1. Башкарма комитет урнашкан урын: Актаныш авылы, Ленин пр., 17.

Урнашу урыны: Актаныш авылы, Ленин пр., 17.

Эш графигы:

дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 7.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр;

җомга: 7.30 сәгатьтән 15.45 сәгатькә кадәр;

шимбә, якшәмбе: ял көннәре

Ял һәм ашау өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмәләр өчен телефон: 8 (85552) 3-44-28, 3-44-22.

Шәхесне раслаучы документлар буенча узу.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - "Интернет" челтәре»): (http:// www.aktanysh.tatar.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук идарәнең урнашкан урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгеләрдән алынырга мөмкин:

1) муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текст мәгълүматын үз эченә алган, мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен идарә биналарында урнашкан мәгълүмат стендлары ярдәмендә. Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.3, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында булган муниципаль хезмәт турындагы мәгълүматларны үз эченә ала;

2) "Интернет"челтәре аша районның муниципаль рәсми сайтында (http:// www. aktanysh. tatar.ru.);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugi. tatar.ru/);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталында (http:// www.gosuslugi.ru/);

5) Башкарма комитетта (Бүлектә):

- телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон буенча;

– язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә - кәгазьдә почта аша, электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен район(-нар) администрацияләре биналарында мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге документлар нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясе Торак кодексының 29.12.2004 ел, №188-ФЗ (алга таба – РФ ТК) (РФ законнары җыелышы, 03.01.2005, №1 (1 өлеш), 14 ст.);

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 29.12.2004 ел, №190-ФЗ (алга таба-РФ ШрК) (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 25.12.2006, № 52 (1 с.), 5498 ст.);

«Россия Федерациясендә архитектура эшчәнлеге турында» 1995 елның 17 ноябрендәге 169-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба – 169-ФЗ санлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 20.11.1995, № 47, 4473);

- 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон (алга таба– 131-ФЗ санлы Закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.10.2003, №40, 3822 статья);

- 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ санлы Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, №31, 4179 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урыны, торак урыны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортның авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне раслау хакында " 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 санлы карары (Россия Федерациясе законнары җыелышы, 06.02.2006, №6, 702 ст.);

"Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы формасын раслау турында"10.05.2011 ел, № 207 РФ төбәк министрлыгы боерыгы(Россия газетасы, № 122, 08.06.2011);

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, № 155-156, 03.08.2004) (алга таба – ТР Законы №45-ТРЗ);

Актаныш муниципаль район Советының 2012 елның 6 маендагы 18-01 санлы карары (алга таба – Устав) белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы);

Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты турында 2006 елның 12 мартындагы 02 санлы нигезләмә (алга таба – Актаныш муниципаль районы Советы карары белән расланган) (алга таба-БК турында Нигезләмә);

Актаныш муниципаль район Советының 25.11.2015 ел, №03-04 санлы карары белән расланган палата турында нигезләмә (алга таба – палата турында Нигезләмә);

Актаныш муниципаль районы Башлыгының 03.02.2009 №2-р санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба-Кагыйдәләр).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

- Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтә урнашкан эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 санлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында»гы карары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр һәм авыл җирлегендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгенең территориаль яктан аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

- техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче органнары тарафыннан җибәрелгән һәм документларга (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның

документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (хата, ялгыш, грамматик яки арифметик хата яки башка шундый хата);

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запрос аңлашыла (27.07.2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 2 статьясындагы 2 нче пункт). Гариза стандарт бланкта тутырыла (1 нче санлы кушымта).

## 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына булган таләпнең атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт атамасы | Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү | РФ ТК 22-24 ст. |
| Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтә торган җирле үзидарә башкарма-боеру органы исеме | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы башкарма комитеты | Башкарма комитет турында нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында белдерү (№2 санлы кушымта) | РФ ТК 23 ст. 5 п.;<br>РФ Хөкүмәтенең 502 санлы карары |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, Россия Федерациясе законнары белән каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору срогы | Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты-бинаны тикшерми генә, 28 көн.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты-бинаны карап чыкканда 30 көн.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | РФ ТК 23 ст. 4 п.; |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив-хокукый актлар, шулай ук гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр, аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру | 1) бүлмәне күчерү турында гариза;<br><br>2) күчермә бүлмәгә хокук билгеләүче документлар (төп нөсхәләр яки нотариаль тәртиптә расланган күчермәләр);<br><br>3) күчерелүче бүлмәнең техник тасвирламасы булган планы (күчерелүче бина торак, мондый бинаның техник паспорты булган очракта);<br><br>4) күчерелә торган бина урнашкан йортның катлар буенча | РФ ТК 23ст. 2 п.; |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | планы;<br><br>5) күчерелүче бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру проекты (үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру мондый бинаны торак яки торак булмаган бина буларак куллануны тәэмин итү өчен кирәк булган очракта);<br><br>6) күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең торак бинаны торак булмаган бинага күчерү турында карары үз эченә алган гомуми җыелышы беркетмәсе;<br><br>7) күчерелә торган бинага тоташкан барлык биналар милекчесенең торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалыгы.<br><br><br>Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бланкын, шәхси мөрәҗәгать итеп, идарәдә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аның белән бергә тапшырыла торган документлар гариза бирүче тарафыннан, түбәндәге ысулларның берсен сайлап, кәгазьдә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>- шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эшләүче зат тарафыннан);<br>-почта аша җибәреп.<br>Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | Ведомствоара бәйләнеш кысаларында алына:<br>1. Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында һәркемгә ачык мәгълүматлар булган) (җир кишәрлегенә хокуклар турында);<br>5) күчерелә торган бинаның техник тасвирламасы күрсәтелгән планы (әгәр күчерелә торган бина торак булса, мондый бинаның техник паспорты бирелә);<br>6) күчерелә торган бина урнашкан йортның катлар буенча планы;<br>4) күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап кителгән документларны таләп итү тыела.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый. | |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда килештерү хезмәт күрсәтү өчен таләп ителгән һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Муниципаль хезмәтләрне килештерү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу буенча сәбәпләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр юк | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) мөрәҗәгать итүче тарафыннан, мөрәҗәгать итүчегә йөкләнгән документлар тапшырылмаган;<br>2) тиешле документ мөрәҗәгать итүче тарафыннан үз инициативасы буенча тапшырылмаган очракта, ведомствоара запроска дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы карамагындагы оешманың муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмавын раслый торган җавабы алыну;<br>3) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;<br>4) бинаны күчерү шартларын үтәмәү;<br>5) торак бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) үзгәртеп планлаштыру проектының закон таләпләренә туры килмәве; | РФ ТК 24 ст. 1 п.; |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләүне исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, әлеге түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос | Чират булганда муниципаль хезмәт алуга гариза бирү – 15 минуттан да артмаска тиеш. | |
| биргәндә һәм мондый хезмәт | Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты | торуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросын теркәү вакыты, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кабул ителгән вакыттан алып бер көн эчендә.<br>Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә килгән мөрәҗәгать, ял (бәйрәм) көненнән соң килә торган эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законына туры китереп, әлеге объектларга инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедия мәгълүматын урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары булган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, язма һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикле мөмкинлеген истә тотып урнаштырыла. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркемгә ачык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү барышында гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән бәйләнешкә керү саны, аларның дәвамлыгы, муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүнең | Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булуы күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>- бүлек бинасының җәмәгать транспортына якын урнашуы;<br>-кирәкле сандагы белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү өчен бүлмәләрнең булуы;<br>-мәгълүмат стендларында, интернет челтәрендә комитетның мәгълүмати ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу; | |

| | | |
|---|---|---|
| күпфункцияле үзәгендә (алга таба - күпфункцияле үзәк), күпфункцияле үзәкнең читтә урнашкан эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | -инвалидларга хезмәтләрдән башкалар белән бер дәрәҗәдә файдаланырга комачаулаучы каршылыкларны узуда ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән билгеләнә:<br>-мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм аларга документларны тапшырганда чиратларның булмавы;<br>-муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары бозылмау;<br>-муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булмау;<br>-муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләрнең булмавы.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм мөрәҗәгать итүченең бер тапкыр аралашуы күздә тотыла. Бәйләнешкә керүнең дәвамлыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – күпфункцияле үзәк) муниципаль хезмәт күрсәткәндә консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне күпфункцияле үзәк белгече башкара.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, күпфункцияле үзәктә алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Муниципаль хезмәтне электрон формада алу тәртибе турында консультацияне интернет кабул итү бүлмәсе яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша алырга мөмкин.<br>Әгәр законда муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт һәм | |

| | | |
|---|---|---|
| | муниципаль хезмәтләр Порталы аша http://uslugi. tatar.ru/) яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең Бердәм порталы (функцияләре) (http:// www.gosuslugi.ru/) аша; | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтә урнашкан эш урыннарында административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы.

3.1.1.Торак бинаны торак булмаган бинага һәм торак булмаган бинаны торак бинага күчерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү;

2) гаризаны кабул итү һәм теркәү;

3)муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм җибәрү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән һәм (яки) телефон аша Бүлеккә муниципаль хезмәт алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече тарафыннан мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр бирелә һәм кирәк булган очракта гариза бланкын тутыруда ярдәм итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гариза бирүче үзе, ышанычлы зат яки КФҮ аша, КФҮнең читтән торып эш урыны аша торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерүгә рөхсәт бирү турында язмача гариза бирә һәм әлеге регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар бүлеккә тапшырыла.

Электрон формада муниципаль хезмәт алу турындагы гариза комитетка электрон почта яки интернет кабул итү аша җибәрелә. Электрон формада алынган гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2. Гаризалар кабул итүне алып баручы Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклау;

- мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен тикшерү (ышаныч кәгазе буенча эш иткән очракта);

- әлеге Регламентның 2.5 нче пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә;

- тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен тикшерү (документларның күчермәләрен тиешенчә ясау, документларда төзәтүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм башка килештерелмәгән төзәтүләрнең булмавы).

Искәрмәләр булмаган очракта Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

- гаризаны кабул итү һәм аны махсус журналда теркәү;

- гариза бирүчедән, аларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, документлар алганлыкка гариза бирүчегә расписка тапшыру;